ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10. 07. 2019 г.Мензелинск № 669

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы
мәгариф системасыныц мониторингын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен
һәм мониторинг күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 августындагы "Мәгариф системасының мониторингын гамәлгә ашыру турында"гы №662 карары һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 15 гыйнварындагы "Мәгариф системасының мониторинг күрсәткечләрен раслау турында"гы №14 боерыгының мәгариф системасына мониторингны гамәлгә ашыру Кагыйдәләренең 4 нче пункты белән расланган, Минзәлә муниципаль район Уставы нигезендә, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы мәгариф системасының мониторингын гамәлгә ашыру Кагыйдәләрен расларга (Кушымта №1).
2. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы мәгариф системасының мониторинг Күрсәткечләрен расларга (Кушымта №2).
3. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
Карарына
Кушымта № 1
№ 669 от 10.07.2019

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район
мәгариф системасы мониторингын гамәлгә ашыру
Кагыйдәләре

1. Гамәлдәге Кагыйдәләр Минзәлә муниципаль районының мәгариф системасы мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен билгелиләр (алга таба текст буенча – мониторинг).

2. Мониторинг мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясенең дәүләт сәясәтен эшкәртү һәм гамәлгә ашыруга мәгълүмати ярдәм, мәгариф үсеше торышына һәм перспективаларына өзлексез системалы анализ һәм бәя бирү (шул исәптән, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге өлешендә), аның өчен кабул ителгән идарә итү карарларының сыйфатын күтәрү хисабына белем бирү системасының эшләү нәтиҗәлелеген көчәйтү максатларында, шулай ук мәгариф турындагы законнар таләпләренең бозылу очракларын ачыклау максатларында гамәлгә ашырыла.

3. Мониторинг мәгариф системасында мәгълүмат җыюны, эшкәртүне, системага салуны һәм алынган мәгълүматны саклауны, шулай ук күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган мәгариф үсеше перспективаларына һәм торышына системалы анализны үз эченә ала (алга таба – мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм анализлау).

4. Мониторингны оештыру “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Мәгариф бүлеге” МКУ тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Мәгариф бүлеге” МКУ мониторинг уздырганда 29.12.2012 елдагы “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы №273-ФЗ Федераль законы белән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм анализлауны үз компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашыра.

Мониторингны оештыру-техник һәм фәнни-методик озату Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башка оешмаларны җәлеп итеп гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Мониторинг федераль статистик күзәтүләр, тикшеренүләр мәгълүматлары нигезендә, шул исәптән, социологик тикшеренүләр, мәгариф эшчәнлеген алып баручы оешмалар эшчәнлеге, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба текст буенча – “Интернет” челтәре) мәгариф оешмаларының рәсми сайтларында урнаштырылган мәгълүмат, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылган мәгълүмат, шулай ук Минзәлә муниципаль районының мәгариф системасы мониторингы

күрсәткечләре нигезендә гражданнардан һәм оешмалардан “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Мәгариф бүлеге” МКУга кергән мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Мониторинг “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Мәгариф бүлеге” МКУ тарафыннан отчет елының 20 декабренә кадәр уздырыла.

8. Мәгариф системасының торышына һәм үсеш перспективаларына уздырылган анализ нәтиҗәләре отчет елыннан соң килүче елның 20 гыйнварына кадәр https://edu.tatar.ru/menzelinsk адресы буенча, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрдә ел саен бастырыла.

9. “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Мәгариф бүлеге” МКУ ел саен, отчет елыннан соң килүче елның 25 октябреннән соңармыйча, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йомгаклау отчетлары тапшыра.